**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
(IV чакырылыш)

чираттан тыш утырыш
**КАРАРЫ**

28 нче декабрь 2023 ел **№ 227** Теләче ав.

Теләче муниципаль район Советының 2019 елның 05 ноябрендәге 200 номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында» нигезләмәне яңа редакциядә раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2023 елның 04 августындагы 416-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе Бюджет кодексының 96.6 һәм 220.1 статьяларына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында, Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларының 2024 елда үтәлү үзенчәлекләрен билгеләү турында» 2023 елның 2 ноябрендәге 520-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Теләче муниципаль район Советы **карар итте:**

1. Теләче муниципаль район Советының 2019 елның 05 ноябрендәге 200 номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында» нигезләмәне яңа редакциядә раслау хакында» карарына (30.07.2020 № 242, 07.10.2021 № 68, 29.04.2022 № 121, 26.06.2023 № 192номерлы карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында Нигезләмәгә:

А) 2024 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 1 гыйнварына кадәр Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында нигезләмәнең 26 статьясындагы 3 пунктының, 29 статьясындагы 3 пунктының гамәлдә булуын туктатып торырга;

Б) 45 статьяның 2 пунктының 2 абзацын:

- түбәндәге эчтәлекле дүртенче һәм бишенче абзацлар белән тулыландырырга:

«җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына авыр йөкле транспорт чаралары китерә торган зыянны каплау исәбенә җирле бюджетларның керемнәре;

авыр йөкле һәм (яисә) эре габаритлы транспорт чарасының хәрәкәт итү кагыйдәләрен бозган өчен җирле бюджетлар керемнәре;»;

- дүртенче - алтынчы абзацларны алтынчы - сигезенче абзацлар дип санарга.

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә. 1 пунктның Б пунктчасының гамәли көче, 2024 елга һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына (2024 елга) бюджеттан башлап, Теләче муниципаль районы бюджетын төзегәндә һәм үтәгәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла.

3. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

Теләче муниципаль
районы башлыгы

Н.Н. Хаҗипов